**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авылы җирлеге советы**
**Карары**

**«20» сентябрь 2018 ел** **№ 79**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авылы җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе, 2018 елның 17нче сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Башкарма комитетының 10 номерлы карары, 2018 елның 20нчы сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 78 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авылы җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авылы җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, (биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларыннан кала) җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган

кешедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

*** Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

*юлларны ремонтлау*

- Олы Салтык авылы, Яңа урам;

- Даныш авылы Полярная урамы.

**- Күмү урыннарын карап тоту:**

- Олы Мәрәтхуҗа авылы зираты коймасын ремонтлау;

**- Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру;**
- каты көнкүреш калдыклары полигоннарын норматив хәлгә китерү:

Олы Салтык авылы,Олы Мәрәтхуҗа авылы, Даныш авылы;

**- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын оештыру;**

- Олы Салтык авылы янгын гидрантларын урнаштыру: Һ. Такташ урамы, Серов урамы;

**- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру;**

- Олы Салтык авылында чишмә ремонты: Г. Тукай урамы.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов ур., 126 йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71,

шулай ук “Волжские зори” (“Идел таннары”) газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Салтык авылы җирлеге башлыгы Х. Х. Ибәтовка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Кама**

**Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авылы җирлеге**
**Башлыгы, Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль**
**районы Олы Салтык авылы**
**җирлеге Советы рәисе** **Х.Х. Ибәтов**